**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Лаеш районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләвен бетерү һәм булдырмауга юнәлтелгән эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар үтәлүгә бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2006 елның 27 мартындагы 90 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы, Лаеш районы, 25 Октябрь исемендәге совхоз поселогы, Почта урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан «Лаеш кошчылык комплексы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте карамагындагы кошчылык предприятиесе территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы барлыкка килүгә бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә өч ай дәвамында барлык кош-корт асраучыларга башка хуҗалыкларга яралгылы йомырка һәм барлык төрдәге тере кош-корт чыгаруны чикләргә.

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Лаеш районының аерым территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2017 елның 10 маендагы ПУ-372 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 09 февраль
№ ПУ-153